КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № б-1817

Россия Федерациясе халыкларының телләрен өйрәнү, киң җәмәгатьчелекнең туган телләрдә язылган документларны ачыклауга һәм саклап калуга карата кызыксынуын уяту максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясе (алга таба – Конференция) турындагы нигезләмәне һәм Татарстан Республикасында «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясен әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын расларга.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасында Конференцияне әзерләү һәм үткәрү барышын яктыртуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 11 июль, 473 нче карары нигезендә Конференция чараларын үткәрү урыннарында шартнамә буенча медицина ярдәме белән тәэмин итүне оештырырга.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына Конференцияне әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Конференция чараларын үткәрү урыннарында гражданнарның иминлеген һәм иҗтимагый тәртипне тәэмин итүдә оештыручыларга ярдәм күрсәтүне.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 сентябрь, б-1817 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында «Туган тел – тарихи хәтер һәм
мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясе турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә 2021 елда Татарстан Республикасында туган телне һәм мәдәни мирасны саклап калуга багышланган «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясен (алга таба – Конференция) оештыру һәм үткәрү тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Конференциянең оештыручысы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

## II. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Конференция Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә язылган документлар белән эшләр комплексы мәсьәләләрен тикшерү һәм туган телләр үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү максаты белән үткәрелә.

2.2. Конференциянең төп бурычлары:

а) Россия Федерациясе халыкларының элек һәм хәзерге вакытта туган телләре кулланылышы өлкәсен яктырту;

б) Россия Федерациясе халыклары телләре үсешенең хәзерге этабында документаль-тарихи мирасны актуальләштерү;

в) милли үзенчәлекләрне, телне һәм мәдәни мирасны саклап калуда документларның ролен билгеләү;

г) Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә язылган документларын тасвирлау һәм фәнни әйләнешкә кертү.

2.3. Конференция принциплары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) үзара хөрмәт һәм тигезлек принципларын;

б) конференция эшенең ачык булу принцибын;

в) әйтелә торган фикерләр, идеяләр һәм тәкъдимнәр өчен җаваплылык принцибын;

г) конференциядә катнашучыларның иҗади инициативасын хуплау принцибын.

2.4. Конференциядә игълан ителгән тематика буенча төп мәсьәләләр яктыртылачак, шулай ук киң фикер алышуга һәм иҗади дискуссияләрдә катнашуга мөмкинлек биреләчәк.

## III. Конференцияне оештыру

3.1. Конференцияне әзерләү һәм үткәрү өчен оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3.2. Оештыру комитеты:

а) Конференцияне үткәрү срокларын, катнашу шартларын, тәртибен һәм форматын билгели;

б) 4.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү срогы башлану көненә кадәр 45 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://arhiv.tatarstan.ru/) Конференция үткәрү турында белдерү урнаштыра;

в) Конференциянең программасын, юнәлешләрен һәм секцияләрен раслый; аны әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияли;

г) Конференция үткәрүне әзерләү һәм тәэмин итү чараларын башкару өчен махсус советлар, төркемнәр, комиссияләр һәм башка органнар оештыра, аларның составына оештыру комитеты әгъзалары һәм башка затлар керергә мөмкин;

д) Конференцияне мәгълүмат белән тәэмин итүне әзерләүне һәм үткәрүне гамәлгә ашыра;

е) Конференция нәтиҗәләрен раслый.

## IV. Конференция үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

4.1. Конференциядә катнашу өчен, Конференция башланганга кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, prm.archive@tatar.ru электрон адресына оештыру комитеты тарафыннан расланган юнәлешләр буенча докладлар текстын, бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча тутырылган катнашучы анкетасын һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана торган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык җибәрергә кирәк. Докладлар файлларына «Фамилия _исем_доклад / анкета» форматында исем бирергә кирәк. Секция докладының регламент вакыты – 7 – 10 минут.

4.2. Конференциядә катнашучы затларга көн тәртибендә тикшерелә торган мәсьәлә буенча мәгълүмат докладлар (хәбәрләр) формасында бирелә.

4.3. Конференциядә катнашучы затлар түбәндәге категорияләргә бүленә:

а) Конференциядә катнашучылар;

б) Конференция җитәкчесе җитәкчелегендә оештыру комитеты;

в) Конференция кунаклары, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары.

4.4. Конференция пленар утырыштан һәм секцияләрдән торачак. Йомгаклау документлары кабул ителгән очракта, йомгаклау утырышы үткәреләчәк.

4.5. Конференциядә турыдан-туры яки читтән торып катнашырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 сентябрь, б-1817 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә 2021 елда Татарстан Республикасында туган телне һәм мәдәни мирасны саклап калуга багышланган «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясен (алга таба – Конференция) оештыру һәм үткәрү тәртибен регламентлаштыра.

1.2. Конференциянең оештыручысы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

## II. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Конференция Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә язылган документлар белән эшләр комплексы мәсьәләләрен тикшерү һәм туган телләр үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү максаты белән үткәрелә.

2.2. Конференциянең төп бурычлары:

а) Россия Федерациясе халыкларының элек һәм хәзерге вакытта туган телләре кулланылышы өлкәсен яктырту;

б) Россия Федерациясе халыклары телләре үсешенең хәзерге этабында документаль-тарихи мирасны актуальләштерү;

в) милли үзенчәлекләрне, телне һәм мәдәни мирасны саклап калуда документларның ролен билгеләү;

г) Россия Федерациясе халыкларының туган телләрендә язылган документларын тасвирлау һәм фәнни әйләнешкә кертү.

2.3. Конференция принциплары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) үзара хөрмәт һәм тигезлек принципларын;

б) конференция эшенең ачык булу принцибын;

в) әйтелә торган фикерләр, идеяләр һәм тәкъдимнәр өчен җаваплылык принцибын;

г) конференциядә катнашучыларның иҗади инициативасын хуплау принцибын.

2.4. Конференциядә игълан ителгән тематика буенча төп мәсьәләләр яктыртылачак, шулай ук киң фикер алышуга һәм иҗади дискуссияләрдә катнашуга мөмкинлек биреләчәк.

## III. Конференцияне оештыру

3.1. Конференцияне әзерләү һәм үткәрү өчен оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3.2. Оештыру комитеты:

а) Конференцияне үткәрү срокларын, катнашу шартларын, тәртибен һәм форматын билгели;

б) 4.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү срогы башлану көненә кадәр 45 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://arhiv.tatarstan.ru/) Конференция үткәрү турында белдерү урнаштыра;

в) Конференциянең программасын, юнәлешләрен һәм секцияләрен раслый; аны әзерләү һәм үткәрү эшләрен координацияли;

г) Конференция үткәрүне әзерләү һәм тәэмин итү чараларын башкару өчен махсус советлар, төркемнәр, комиссияләр һәм башка органнар оештыра, аларның составына оештыру комитеты әгъзалары һәм башка затлар керергә мөмкин;

д) Конференцияне мәгълүмат белән тәэмин итүне әзерләүне һәм үткәрүне гамәлгә ашыра;

е) Конференция нәтиҗәләрен раслый.

## IV. Конференция үткәрүнең төп шартлары һәм тәртибе

4.1. Конференциядә катнашу өчен, Конференция башланганга кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, prm.archive@tatar.ru электрон адресына оештыру комитеты тарафыннан расланган юнәлешләр буенча докладлар текстын, бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча тутырылган катнашучы анкетасын һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслана торган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык җибәрергә кирәк. Докладлар файлларына «Фамилия _исем_доклад / анкета» форматында исем бирергә кирәк. Секция докладының регламент вакыты – 7 – 10 минут.

4.2. Конференциядә катнашучы затларга көн тәртибендә тикшерелә торган мәсьәлә буенча мәгълүмат докладлар (хәбәрләр) формасында бирелә.

4.3. Конференциядә катнашучы затлар түбәндәге категорияләргә бүленә:

а) Конференциядә катнашучылар;

б) Конференция җитәкчесе җитәкчелегендә оештыру комитеты;

в) Конференция кунаклары, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары.

4.4. Конференция пленар утырыштан һәм секцияләрдән торачак. Йомгаклау документлары кабул ителгән очракта, йомгаклау утырышы үткәреләчәк.

4.5. Конференциядә турыдан-туры яки читтән торып катнашырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 сентябрь, б-1817 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында «Туган тел – тарихи хәтер һәм мәдәни мирас чыганагы» бөтенроссия фәнни конференциясен әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразыев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлахов Мәгъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Мостафин Данил Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шәрипов Ирек Илдус улы | «Татарстан халыклары дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Яковлев Константин Геннадиевич | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |